Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге составына керүче
Монашево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

17.11. 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 120 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә 18.00 сәг.Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегендә гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авылы җирлегенең Монашево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы? дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

1.Ленин, Михаил Петров һәм Заречная урамнарын вак таш җәю (ташу һәм тигезләү)

2.Урам яктырту лампаларын урнаштыру;

3.Янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр һәм буяу сатып алу;

4.Янгын сүндерү машинасына хезмәт күрсәтүче шоферның хезмәтләре өчен түләү.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 224 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 118 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ"  - 118 граждан тавыш бирде;

"ЮК"   - 0 граждан.

Бәян ителгәннәр нигезендә,  гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган  дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Монашево авылы җирлегенең Монашево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә,  I-II төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы? дигән сорауга карарны танырга

1.Ленин, Михаил Петров һәм Заречная урамнарын вак таш җәю (ташу һәм тигезләү)

2.Урам яктырту лампаларын урнаштыру;

3.Янгын сүндерү машинасы   өчен запас частьләр һәм буяу сатып алу;

4.Янгын сүндерү машинасына хезмәт күрсәтүче шоферның хезмәтләре өчен түләү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Монашево авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы

Монашево авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Иосифов